**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.08.2020 **Чирмешән авылы** **№** 332

**Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018 елның
31 маенда кабул ителгән 226 номерлы
«Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
торак сәясәте бүлеге тарафыннан
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын
раслау турында» карарына
үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карарына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 31 маенда кабул ителгән 226 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарының 2 номерлы кушымтасына

үзгәрешләр кертергә һәм кушымтада күрсәтелгән түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

2. Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә өч эш көне эчендә 1 пунктта расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук муниципаль берәмлекләр порталында, Чирмешән муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Башкарма комитет

Җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта

11 август 2020 ел № 332

**Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү).

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: торак урыннарына мохтаҗ физик затлар (алга таба-мөрәҗәгать итүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы - Башкарма комитетның торак сәясәте бүлеге (алга таба - Бүлек).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: ТР, Чирмешән районы, Чирмешән авылы, Совет ур., 32;

Бүлекнең урнашу урыны: ТР, Чирмешән районы, Чирмешән авылы, Совет ур., 32.

Башкарма комитетның Бүлегенең эш графигы: һәр көнне 8.00-17.00, шимбә һәм якшәмбедән кала, 12.00-13-00 - төшке аш.

1.3.2. Бүлекнең белешмә телефоны: (84396) 22369

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Башкарма комитетның рәсми сайты адресы: http://cheremshan.tatarstan.ru/.

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текст мәгълүматларын үз эченә алган мәгълүмати стендлар ярдәмендә. Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларда (пунктчаларда) булган муниципаль хезмәт турында белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша

Башкарма комитетның рәсми сайтында (http://cheremshan.tatarstan.ru/);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Башкарма комитетка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Башкарма комитетка язма (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Башкарма комитетның рәсми сайтында һәм Башкарма комитет бинасындагы гариза бирүчеләр белән эшләү өчен мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Торак кодексы (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеш), 14 ст.) (алга таба – РФ ТК);

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);

1995 елның 12 гыйнварындагы 5 – ФЗ номерлы «Ветераннар турында» федераль закон (алга таба- 5-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелышы, 16.01.1995, № 3, 168 ст.);

1995 елның 24 ноябрендәге 181 – ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон (алга таба-181-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелышы, 27.11.1995, № 48, 4563 ст.);

1996 елның 21 декабрендәге 159 – ФЗ номерлы «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль закон (алга таба-159-ФЗ номерлы федераль закон) (РФ законнары җыелышы, 23.12.1996, № 52, 5880 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы «Россия Федерациясе гражданнарын үтемле һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында» карары;

2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, № 259-260, 31.12.2004) (алга таба – 69-ТРЗ номерлы ТР законы);

2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, № 144, 20.07.2007);

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы « Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата – ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, шулай ук ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан үзләренә беркетелгән торак урыны булмаган затларны торак белән тәэмин итү чаралары турында» карары (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары ҖЫЕНТЫГЫ, 11.06.2008, № 22, 0865 ст.);

Чирмешән муниципаль район Советының 2010 елның 7 августындагы 191 номерлы карары белән кабул ителгән, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав).

1.5. Әлеге Регламентта, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ Россия Федерациясе гражданнарының аерым категорияләрен исәпкә алу астында гражданнарны торак белән тәэмин итү карала, аларның исемлеге федераль норматив хокукый актлар һәм Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән.

торак хокуклары объектлары - торак биналар:

торак йорт, торак йортның бер өлеше - бүлмәләрдән, шулай ук гражданнар тарафыннан мондый бинада яшәүгә бәйле көнкүреш һәм башка ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен билгеләнгән ярдәмче куллану урыннарыннан торган индивидуаль-билгеләнгән бина;

фатир, фатирның бер өлеше - күпфатирлы йортта гомуми файдаланудагы биналарга турыдан-туры керү мөмкинлеген тәэмин итә торган һәм бер яки берничә бүлмәдән, шулай ук гражданнар тарафыннан мондый аерым билгеләнгән бинада яшәү белән бәйле көнкүреш һәм

башка ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен билгеләнгән ярдәмче куллану урыннарыннан торган күпфатирлы йорттагы структур-аерымланган урын;

бүлмә - торак йортта яки фатирда гражданнарның турыдан-туры яшәү урыны буларак файдалану өчен билгеләнгән торак йортның яки фатирның өлеше.

муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация үткәрү урыны;

техник хата - муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән мәгълүматларның (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе), документлардагы мәгълүматлар нигезендә кертелгән мәгълүматларның тиешле таләпләргә туры килмәвенә китергән хата (описка, опечатка, грамматик яки арифметик хата яисә шундый хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) астында муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату (запрос) аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 п.). Гариза стандарт бланкта тутырыла (административ регламентка 1нче кушымта).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую | РФ ТК 51 ст.;<br>5-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карары |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органының исеме | Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты | |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Чиратта торучылар исемлегенә кертү турында карар.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ ТК 51 ст.;<br>5-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карары |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Материалларны торак комиссиясенә карауга әзерләү - 25 көн[1] .<br>«Татарстан Республикасы буенча гражданнарның җыелма исемлегенә яңа гариза бирүчеләрне гаилә әгъзалары белән теркәү турында» карар чыгарылышы - 8 көн.<br>Мөрәҗәгать итүчегә Татарстан Республикасы буенча гаиләләр реестрына кертү турында карар кабул ителгәннән соң ике көннән дә артмыйча хәбәр итү.<br>Комиссиянең чираттагы утырышын көтү вакыты һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды коммерциячел булмаган оешмасының административ процедураларны үтәү вакыты» хезмәт күрсәтү вакытына керми.<br>Комиссия утырышлары айга бер тапкыр уза<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктатып тору каралмаган | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый | 1) Гариза;<br>2) Шәхесне раслаучы документлар; | |

[1] Процедураларның озынлыгы эш көннәрендә исәпләнә

| | | |
|---|---|---|
| актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге | 3) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил гамәл кылса);<br>4) Мөрәҗәгать итүчене һәм аның гаиләсен торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар (административ регламентка 2 нче кушымта), дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм ведомствоара хезмәттәшлек буенча алынырга мөмкин булган башка оешмалар карамагында булган документлардан тыш.<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат);<br>почта аша җибәреп.<br>Гариза һәм документлар, шулай ук, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тәкъдим ителергә (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>1) Хәрби хезмәт узу, шулай ук аңа тиңләштерелгән Россия Федерациясенең 1993 елның 12 февралендәге 4468-1 номерлы Законында каралган башка хезмәт чоры турында (хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнар өчен) белешмәләр:<br>2) Йорт кенәгәсеннән өземтә (документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән очракта);<br>3) Торак һәм гомуми торак мәйданы һәм бирү датасы күрсәтелгән финанс-шәхси счет (әгәр документ җирле | |

| | | |
|---|---|---|
| | үзидарә органнары тарафыннан бирелә икән).<br>4) Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан Ерак Төньяк районнарында һәм аларга тиңләштерелгән урыннарда эшләү чорларының дәвамлылыгы турында белешмә, аларны исәпкә алып, тиешле нигез буенча пенсия алу хокукы билгеләнә һәм (яки) пенсия күләме исәпләнә (Ерак Төньяк районнарыннан чыккан гражданнар өчен);<br>5) Гражданның даими яшәү урыны буенча халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының гражданны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында белешмәсе, гражданны андый дип тану датасын күрсәтеп - эшсезләр өчен (Ерак Төньяк районнарыннан чыккан гражданнар өчен);<br>6) Аерым затның элек булган (үзенең) күчемсез милек объектларына хокуклары турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (ата – аналары белән яшәүче һәм үз гаиләләрен кормаган биш һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр өчен) (ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен);<br>7) Даими яшәү өчен торак урыны, торак төзү (сатып алу) өчен ссуда яки субсидияләр яисә мәҗбүри күченүчеләр тарафыннан (мәҗбүри күченүчеләр дип танылган гражданнар өчен) югалган торак өчен компенсация алу (алмау) турында белешмә.<br>8) I һәм II төркем инвалидлар, шулай ук балачактан инвалидлар өчен - инвалидлык турында медик-социаль экспертиза учреждениесе белешмәсе (Ерак Төньяк районнарыннан чыккан гражданнар өчен)<br>Мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела: | |

| | | |
|---|---|---|
| | 1. дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда аталган документларны.<br>2. муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, яки муниципаль хезмәтне күрсәткәндә кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирүне, түбәндәге очраклардан тыш:<br>а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны беренче тапкыр биргәннән соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләрен үзгәртү;<br>б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле һәм элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән документларны кабул итүдән беренчел баш тартканнан соң мөрәҗәгать итүче биргән документларда хаталар булу;<br>в) документларның гамәлдә булу вакыты чыккан яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, йә муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканнан соң мәгълүматның үзгәрүе;<br>г) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, оешма хезмәткәре тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тарткан очракта хата яки хокукка каршы гамәл кылуның (гамәл кылмау) документаль расланган фактын (билгеләрен) ачыклау, бу хакта язма рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тарткан очракта күпфункцияле үзәк җитәкчесе, | |

| | | |
|---|---|---|
| | яки оешма җитәкчесе имзасы белән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тормый, киләсе очрактан тыш, әгәр тиешле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмыйча, дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына караган оешманың муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмауны таныклаучы ведомствоара соратуга җавабы килсә, мондый соратып алына торган документларның яисә мәгълүматның мондый органнар яки оешмалар карамагында булмавы тиешле гражданнарның муниципаль хезмәт алуга хокукын раслый торган очраклардан тыш. | |
| 2.7. Дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге, норматив хокукый актларда каралган очракларда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен аларның килештерүе таләп ителә һәм ул муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан башкарыла | Чиратта торучылар исемлеге Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды (алга таба – Дәүләт торак фонды) белән килештерелә | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Тиешле булмаган зат тарафыннан документларны тапшыру;<br>2) Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага кушып бирелә торган | |

| | | |
|---|---|---|
| | документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген төгәл аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди зыяннар бар;<br>4) Тиешсез органга документларны тапшыру | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә алу хокукын расламаган документларны тапшыру;<br>2) Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган, йә гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар;<br>3) Гражданнар тарафыннан торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын алу нияте белән торак шартларының начарлануына китергән ниятләнгән гамәлләр кылган көннән вакыт (биш ел ) үтмәде;<br>4) Әгәр тиешле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаган булса, дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына караган оешманың муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмауны таныклаучы ведомствоара соратуга җавабы килүе. | РФ ТК 53 ст. |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Чират булган очракта муниципаль хезмәт алуга гариза бирү - 15 минуттан да артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратта максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соратуын теркәү срогы | Гариза кергәннән соң бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән соратып алу ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтү биналарына карата таләпләр | Муниципаль хезмәт янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм йортларда (в зданиях и помещениях) күрсәтелә.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтәге эш урыннарында муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге, | Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бүлек бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашуы;<br>белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү башкарыла торган бүлмәләр кирәкле санда булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана: | |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып | мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирү өчен чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтләренә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату (запрос) биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның да, мөрәҗәгать итүченең дә бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек озынлыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, документларны кабул итү һәм бирү эшен КФҮ белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталында, КФҮтә алынырга мөмкин | |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәт күрсәтүне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Законда муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон формада гариза бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелә (http://uslugi. tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/) | |

**3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактан торып эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре**

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә хәрәкәт тәртибен тасвирлау

3.1.1. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация үткәрү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) торак шартларын тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану;

4) муниципаль хезмәтне күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны (запросы) формалаштыру һәм җибәрү;

5) документларны торак комиссиясе каравына җибәрү;

6) комиссия тарафыннан материалларны карау;

7) чираттагылар исемлегенә кертү турында карар проектын әзерләү, исемлекне формалаштыру;

8) мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында белдерү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнең блок-схемасы 3нче кушымтада тәкъдим ителгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр үткәрү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультацияне алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон аша яки Интернет-кабул итү аша мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирә, шул исәптән, муниципаль хезмәт алу өчен бирелә торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр, кисәтүләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат яисә КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында Бүлеккә гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны тапшыра. Документлар ерактан торып эш урыны аркылы тапшырылырга мөмкин. Ерактан торып эш урыннары исемлеге 4нче кушымтада китерелгән.

3.3.2. Гаризалар кабул итүче Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү;

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышанычнамә буенча гамәл кылган очракта);

әлеге Регламентның 2.5 пункты белән каралган документларның барлыгын тикшерү;

бирелгән документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда өзеклекләр (подчистка), припискалар, сызып алынган сүзләр һәм башка килешмәгән төзәтмәләр булмау).

Шелтәләр булмаган очракта Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаларны кабул итү һәм махсус журналда теркәү;

мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларның исемлеге күчермәләрен, документларны кабул итү датасы, кергәндә бирелгән номеры, муниципаль хезмәт күрсәтүнең датасы һәм вакыты турында билге белән тапшыру;

гаризаны Башкарма комитет җитәкчесенә карап тикшерү өчен җибәрү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, документларны кабул итүне алып баручы Бүлек белгече, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен киртәләр булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гамәлгә ашырыла:

гаризалар һәм документлар 15 минут эчендә кабул ителә;

гаризаны теркәү гариза кергәннән соң бер көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрелгән яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм гаризаны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Гражданны торак шартларын тикшерү нәтиҗәләре буенча мохтаҗ дип тану

3.4.1. Бүлек башлыгы кергән гаризаларны карый һәм документларны Бүлек белгеченә җибәрү яки торак шартларын тикшерү турында карар кабул итә.

Торак шартларын тикшерү турында карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет җитәкчесенең комиссия составын раслау турындагы карар проектын әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә җибәрелгән документлар яки комиссия составын раслау турында карар проекты.

3.4.2. Башкарма комитет җитәкчесе комиссия составын раслый һәм карарны комиссия рәисенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карар проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: комиссия рәисенә җибәрелгән карар.

3.4.3. Комиссия рәисе гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының торак шартларына комиссия тикшерүе үткәрүне оештыра. Торак шартларын тикшерү нәтиҗәләре буенча, учетка алу (алудан баш тарту) турында бәяләмә белән, билгеләнгән формадагы торак шартларын тикшерү акты төзелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карар алынганнан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән тикшерү акты.

3.4.4. Бүлек белгече гражданны торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алу (кабул итүдән баш тарту) турында комиссия бәяләмәсе нигезендә:

әгәр гражданин мохтаҗ дип табылса, исәпкә алу эшен формалаштыра;

әгәр гражданин мохтаҗ түгел дип табылса, Башкарма комитет җитәкчесендә хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хатны имзалый һәм тикшерү акты һәм бәяләмә белән гариза бирүчегә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар тикшерү уздырганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: формалаштырылган эш яки баш тарту турында хат.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү

3.5.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәгеләрне тәкъдим итү турында запросларны җибәрә:

1) Хәрби хезмәт узу чоры, шулай ук аңа тиңләштерелгән Россия Федерациясенең 1993 елның 12 февралендәге 4468-1 номерлы законында каралган башка хезмәт турында белешмәләр (хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнар өчен):

2) Йорт кенәгәсеннән өземтә (документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән очракта);

3) Торак һәм гомуми торак мәйданын һәм бирү датасын күрсәтеп финанс-шәхси счет (әгәр документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә икән).

4) Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан Ерак Төньяк районнарында һәм аларга тиңләштерелгән урыннарда эшләү чорларының дәвамлылыгы турында белешмә, аларны исәпкә алып, тиешле нигез буенча пенсия алу хокукы билгеләнә һәм (яки) пенсия күләме исәпләнә (Ерак Төньяк районнарыннан чыккан гражданнар өчен);

5) Гражданның даими яшәү урыны буенча халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының гражданны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында белешмәсе, гражданны андый дип тану датасын күрсәтеп - эшсезләр өчен (Ерак Төньяк районнарыннан чыккан гражданнар өчен);

6) Аерым затның элек булган (үзенең) күчемсез милек объектларына хокуклары турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан (ата – аналары белән яшәүче һәм үз гаиләләрен кормаган биш һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр өчен) (ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен);

7) Даими яшәү өчен торак урыны, торак төзү (сатып алу) өчен ссуда яки субсидияләр яисә мәҗбүри күченүчеләр тарафыннан (мәҗбүри күченүчеләр дип танылган гражданнар өчен) югалган торак өчен компенсация алу (алмау) турында белешмә.

8) Дәүләт медик-социаль экспертиза хезмәте органнарының инвалидлык турында белешмәсе - I һәм II төркем инвалидлар өчен, шулай ук балачактан инвалидлар өчен.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында запрослар.

3.5.2. Белешмәләр белән тәэмин итүчеләр белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, соратып алына торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамәләр (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

Росреестр белгечләре җибәргән документлар (белешмәләр) буенча өч эш көненнән дә артмый;

калган тәэмин итүчеләр буенча - документлар һәм мәгълүмат бирүче органга яки оешмага ведомствоара запрос килгән көннән биш көн эчендә, әгәр ведомствоара сорауга җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнмәсә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән соралган белешмәләр, яисә баш тарту турында хәбәрнамә.

3.6. Документларны торак комиссиясе каравына җибәрү.

3.6.1. Кергән мәгълүматлар нигезендә Бүлек белгече:

тапшырылган документлардагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерә;

гаиләнең хисап эшен рәсмиләштерү (барлык документларны аерым папкага комплектацияләү);

әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын тикшерү. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Бүлек белгече муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында бәяләмә әзерли. Бәяләмә гаиләнең хисап эшенә куела.

гаиләнең хисап эшен иҗтимагый торак комиссиясе (алга таба – комиссия) карап тикшерүенә җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар запросларга җаваплар кергән вакыттан алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: комиссия каравына җибәрелгән хисап эше.

3.7. Комиссия тарафыннан материалларны карау;

3.7.1. Комиссия секретаре башкара:

кергән документлар белән танышу;

комиссия утырышы көнен билгеләү;

комиссия әгъзаларына комиссия утырышы көне турында хәбәр итү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар документлар кергән мизгелдән ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: комиссия әгъзаларына комиссия утырышы көне турында хәбәр итү.

3.7.2. Комиссия үзенең утырышында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ аерым категория гражданнарны исәпкә кую яисә исәпкә куюдан баш тарту турында карар кабул итә. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура комиссия утырышы көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар комиссия утырышы көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: учетка кую яки куюдан баш тарту турында карар

3.7.3. Комиссия секретаре комиссия карарын беркетмә рәвешендә рәсмиләштерә (2 нөсхә) һәм имзаларга комиссия әгъзаларына тапшыра.

Процедуралар комиссия утырышы көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзага бирелгән бәяләмә.

3.7.4. Комиссия әгъзалары беркетмәгә имза куялар һәм комиссия секретаренә юллыйлар.

Процедуралар комиссия утырышы көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган бәяләмә.

3.7.5. Комиссия секретаре комиссия беркетмәсен Бүлек белгеченә гаиләнең исәпкә алу эше белән бергә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура карар кабул ителгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә җибәрелгән комиссия беркетмәсе һәм исәп эше.

3.8. Чираттагылар исемлегенә кертү турында карар проектын әзерләү, исемлекне формалаштыру

3.8.1. Бүлек белгече комиссия тарафыннан исәпкә кую турында карар кабул ителгән очракта:

мөрәҗәгать итүченең (никахта тормаган мөрәҗәгать итүченең) гаиләсе турында Татарстан Республикасы буенча гражданнарның җыелма исемлегенә кертә («Исәпкә алу эшен теркәү» карточкасын төзи, мөрәҗәгать итүчегә исәп номерын бирә);

«Татарстан Республикасы буенча гражданнарның җыелма исемлегенә гаилә әгъзалары белән яңа мөрәҗәгать итүчеләрне теркәү турында» карар проектын әзерли (алга таба – карар).

Комиссия исәпкә куюдан баш тарту турында карар кабул иткән очракта, Бүлек белгече учетка куюдан баш тарту турында хат проектын әзерли (алга таба-хат) һәм килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар беркетмә һәм гаиләне исәпкә алу эше кергән вакыттан алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән карар (хат) проекты.

3.8.2. Бүлек җитәкчесе карар (хат) проектын килештерә һәм имзага Башкарма комитет җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән карарның (хатның) килешенгән проекты.

3.8.3. Башкарма комитет җитәкчесе карарны (хатны) имзалый һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән имзаланган карар (хат).

3.8.4. Бүлек белгече карарны алгач документларны туплый һәм Дәүләт торак фондына җибәрә.

Исәпкә куюдан баш тарткан очракта, имзаланган хат гариза бирүчегә почта аша, комиссия карарын кушып белән җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрелгән документлар яки баш тарту турында хат.

3.8.5. Дәүләт торак фонды документларны кабул итә һәм гамәлгә ашыра:

торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү өлкәсендә үзара хезмәттәшлек турында төзелгән шартнамәләр, дәүләт җир резервын формалаштыру һәм алардан файдалану тәртибе нигезендә аларны анализлау һәм гомумиләштерү;

исәпкә куелган гаиләләр (шулай ук никахлашмаган гариза бирүчеләр) реестрын формалаштыру, шәһәрләр һәм районнар буенча бүленеш белән;

исәпкә куелган гражданнарның формалаштырган реестрын, яисә исәпкә куелудан баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, гражданнарның бирелгән исемлекләрен Бүлеккә кире кайтару.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды регламенты белән билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: учетка кую яки сәбәпләрен күрсәтеп учетка куюдан баш тарту турында карар.

3.9. Мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында белдерү.

3.9.1. Дәүләт торак фондыннан документлар алгач, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ аерым категория гражданнарны исәпкә кую һәм Дәүләт торак фонды реестрына кертү яки исәпкә куюдан баш тарту турында хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карар кабул ителгән көннән ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә исәпкә кую яки куюдан баш тарту турында хәбәр итү.

3.10. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.10.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен КФҮкә, КФҮнең ерактан торып эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.10.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү билгеләнгән тәртиптә расланган КФҮ эше регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.10.3. КФҮтән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар килгәч, процедуралар әлеге Регламентның 3.3-3.8 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮкә җибәрелә.

3.11. Техник хаталарны төзәтү.

3.11.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торучы, документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Бүлеккә тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (Административ регламентка 5нче кушымта);

техник хатасы булган, гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, документ;

юридик көчкә ия, техник хаталар булуын таныклаучы, документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән үзе, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), йә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша бирә.

3.11.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушып бирелгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә карауга юнәлдерелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.11.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында әлеге Регламентның 3.8 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүченең (аның вәкиленең) шәхсән имзасы белән бирә техник хата булган документның оригиналын алып калу белән, яки мөрәҗәгать итүчегә почта аша (электрон почта аша) документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә Бүлеккә техник хатасы булган документның оригиналын тапшырганда.

Әлеге пунктча белән билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып торалар:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып, проектларны визалау тора;

2) эш башкаруны (делопроизводство) алып баруны тикшерүне билгеләнгән тәртиптә үткәрүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин (комплекслы тикшерүләр), яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең башкарылуын контрольдә тоту өчен һәм карарлар кабул иткәндә Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар тарафыннан билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, шулай ук Башкарма комитет белгечләре тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылык тота.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр Законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан тикшереп тору муниципаль хезмәт күрсәткәндә җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затына яисә муниципаль хезмәткәргә, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәк хезмәткәренә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмаларга яисә аларның хезмәткәрләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

### 5.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) предметы

5.1. Мөрәҗәгать итүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән таләпне, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросны теркәү срокларын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә, 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яки аларны гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда бирүе каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, законнарда һәм Россия Федерациясе субъектларының башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре каралмаган булса.

Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

6) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтүдән муниципаль хезмәт күрсәтүче органның муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, яисә аларның хезмәткәрләренең баш тартуы яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срокларын бозу. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срокларын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, законнарда һәм Россия Федерациясе субъектларының башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору нигезләре каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

10) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тарткан булмавы һәм (яисә) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны яисә белешмәләрне мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә таләп итү, Федераль законда каралган очраклардан тыш. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә Федераль законда билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләрне күрсәтү функциясе йөкләнгән булса.

5.1.2. Шикаятьне бирү һәм карау тәртибенә гомуми таләпләр

1. Шикаять язмача кәгазьдә, электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә йә күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы гавами-хокукый берәмлекнең дәүләт хакимиятенең тиешле органына (җирле үзидарә органына) (алга таба- күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр югары органга (булган очракта) бирелә яисә ул булмаганда, турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла. Күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга яисә Россия Федерациясе

субъектының норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә тапшырыла.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүченең шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Күп функцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүченең шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Әлеге Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүченең шәхси кабул итүе вакытында кабул ителергә мөмкин.

3. Башкарма хакимиятнең федераль органнары, дәүләт корпорацияләре һәм аларның вазыйфаи затлары, федераль дәүләт хезмәткәрләре, Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондларының вазыйфаи затлары, Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның һәм аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрне, шулай ук күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрне бирү һәм карау тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

3.1. Әгәр федераль закон тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның вазыйфаи затларының яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның яисә муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрне бирү һәм карау тәртибе (процедурасы) федералль закон белән билгеләнсә, күрсәтелгән шикаятьләрне бирү һәм карау белән бәйле мөнәсәбәтләр өчен Федераль законның 11.1 статьясы һәм әлеге статьяның нормалары кулланылмый.

3.2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган төзелеш өлкәсендәге процедураларның тулы исемлегенә кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның вазыйфаи затларының, яисә муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм (яисә) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять мондый затлар тарафыннан әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә, йә Россия Федерациясенең монополиягә каршы законнары белән билгеләнгән тәртиптә монополиягә каршы органга тапшырылырга мөмкин.

4. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының дәүләт граждан хезмәткәрләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең, җирле үзидарә органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына), шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләрне бирү һәм карау

үзенчәлекләре Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

5. Шикаять түбәндәге мәгълүматны тупларга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәренең, Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләре һәм (яки) хезмәткәрләре исемен;

2) мөрәҗәгать итүче - физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар, йә мөрәҗәгать итүче - юридик затның атамасы, урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең хезмәткәренең, Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәве турында дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләренраслаучы документлар (булганда), йә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

6. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күп функцияле үзәккә, күп функцияле үзәкне гамәлгә куючыга, Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмага яисә югарыдагы органга (булган очракта) кергән шикаять, аны теркәгән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә һәм аны теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдә йә җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срокларын бозуга карата шикаять белдерелгәндә – аны теркәгәннән көннән биш эш көне эчендә.

7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән, кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм опечаткаларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

8. Әлеге пунктның 7 өлешендә күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

8.1. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, Федераль законда күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күп функцияле үзәк яисә Федераль законда каралган оешма тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында кирәкле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

8.2. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану очрагында, Федераль законда күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

9. Шикаятьне тикшерү барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составының билгеләре ачыкланган очракта, әлеге пунктның 1 өлеше нигезендә шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

10. Әлеге Федераль законның муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гражданнар һәм оешмаларның хокукларын бозуга карата шикаятьләрне карау тәртибен билгеләүче нигезләмәләре 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль закон белән җайга салына торган мөнәсәбәтләргә кагылмый.

5.1.3. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүнең мәгълүмат системасы

Россия Федерациясендә судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү буенча федераль мәгълүмат системасы булдырыла, ул федераль дәүләт мәгълүмат системасы булып тора. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү федераль мәгълүмат системасын булдыру һәм аның эшчәнлеге федераль законнар һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары белән җайга салына.

1нче кушымта

Административ регламентка

Башкарма комитет җитәкчесенә ____________

(муниципаль берәмлекнең

______________________________

җирле үзидарә органы исеме)

(кемнән)

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

(алга таба - мөрәҗәгать итүче).
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, паспорт белешмәләре, яшәү урыны буенча теркәлү, телефон)

**Торак урыннарына**
**мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую турында**
**ГАРИЗА**

Бәйле рәвештә______________________________________________

(торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкның сәбәпләрен

______________________________________________

күрсәтергә: гаиләнең бер әгъзасына торак мәйданы белән

______________________________________________

билгеләнгән дәрәҗәдән түбәнрәк тәэмин ителү, санитар һәм

______________________________________________

техник таләпләргә җавап бирми торган торак урынында яшәү,

______________________________________________

тулай торакта яшәү, поднайм шартларында яшәү һ. б.)

Чирмешән муниципаль районының торак мәсьәләләре буенча иҗтимагый комиссиясе фикер алышуына исәпкә алу турындагы үтенечемне кертүегезне сорыйм

______________________________________________

мине, (гаиләмне) торак мәйданы алу (торак шартларын яхшырту) өчен.

Үзем турында хәбәр итәм, мин эшлим ______________________________________

______________________________________________

(оешманың исемен күрсәтергә)

____________________19___елдан бирле

__________________________________________ вазыйфасында.

Минем гаиләм __________ кешедән тора (туганлыгын, яше буенча, кайсы вакыттан бирле яшәгәнен күрсәтергә)_____________________________________________

______________________________________________

**Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:**

1) Шәхесне раслаучы документлар;

2) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил гамәл кылса);

3) Анкета.

4) Мөрәҗәгать итүчене һәм аның гаиләсен торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар.

Соратып алганда сканерланган документларның оригиналларын тапшырырга дип өстемә йөкләмә алам.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | ____________ | ____________________________________________ |
| (дата) | (имза) | (Фамилия, исем, әтисенең исеме) |

2нче кушымта
Административ регламентка

**Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую мәсьәләсен карау өчен кирәкле документлар исемлеге****

1. Хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнар:
хәрби хезмәтнең (хезмәтнең) гомуми озынлыгы турында белешмә;
хәрби хезмәттән (хезмәттән) азат ителгән һәм федераль органда торак урыннарына мохтаҗлар исәбендә торучы гражданнар өчен - эштән азат ителү нигезен күрсәтеп, хәрби хезмәттән (хезмәттән) азат итү турында боерыктан өземтә;
торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында торак урыннарын исәпкә алу һәм бүлү органы карарыннан өземтә, киләсе гражданнардан тыш (ябык хәрби шәһәрчекләрдән күчерелергә тиешле гражданнар, пенсия хокукы белән хәрби хезмәттән азат ителгән һәм әлеге торак пунктны ябык хәрби шәһәрчекләр исемлегеннән төшереп калдырганчы торак пунктларда яшәүче гражданнар);
ябык хәрби шәһәрчек (бистә) территориясендә яшәү турында белешмә - шундый шәһәрдә (бистәдә) яшәүче гражданнар өчен;
торак урынының өстәмә мәйданына хокукны раслаучы документ күчермәсе (мондый хокук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очракларда);
гаиләнең һәр әгъзасының шәхесен раслаучы документлар күчермәләре;

2. Чернобыль АЭСда катнашучы гражданнар
гражданның федераль бюджет чаралары исәбеннән торак урыны белән тәэмин итү хокукын раслый торган документ;
торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында торакны исәпкә алу һәм бүлү органы карарыннан өземтә;
торак урынының өстәмә мәйданына хокукны раслаучы документ күчермәсе (мондый хокук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очракларда);
гаиләнең һәр әгъзасына шәхесне раслаучы документлар күчермәләре;

3. Мәҗбүри күченүчеләр дип танылган гражданнар
күрсәтелгән статуска ия булган гаиләнең һәр балигъ булган әгъзасына мәҗбүри күченүче таныклыгы күчермәсе;
даими яшәү өчен торак урыны, торак урыны төзүгә (сатып алуга) ссуда яки социаль түләү яисә югалган торак урыны өчен компенсация алу (алмау) турында миграция өлкәсендә контроль органы белешмәсе;
торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында торакны исәпкә алу һәм бүлү органы карарыннан өземтә;
торак урынының өстәмә мәйданына хокукны раслаучы документ күчермәсе (мондый хокук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очракларда);
гаиләнең һәр әгъзасына шәхесне раслаучы документлар күчермәләре;

4. Ерак Төньяк районнарыннан чыккан гражданнар
1992 елның 1 гыйнварына кадәр Ерак Төньяк районнарына яки аларга тиңләштерелгән җирләргә килү фактын раслаучы документлар;
Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдән күченүгә бәйле рәвештә торак субсидияләре алу хокукына ия булган гражданнарны исәпкә алу органы карарыннан өземтә;
Ерак Төньяк районнарында һәм аларга тиңләштерелгән урыннарда хезмәт стажын раслаучы документлар күчермәләре;
пенсия таныклыгы күчермәсе яисә пенсия тәэминатын гамәлгә ашыручы органнан пенсия тәэминаты турында белешмә, шулай ук Россия Федерациясе Пенсия фондының

территориаль органыннан Ерак Төньяк районнарында һәм аларга тиңләштерелгән урыннарда эш стажының гомуми озынлыгы турында белешмә - пенсионерлар өчен;

гражданның даими яшәү урыны буенча халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының гражданны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында белешмәсе, аны мондый дип тану датасын күрсәтеп;

торак урынының өстәмә мәйданына хокукны раслаучы документ күчермәсе (мондый хокук Россия Федерациясе законнары белән бирелгән очракларда);

гаиләнең һәр әгъзасына шәхесне раслаучы документлар күчермәләре;

мөрәҗәгать итүченең Ерак Төньяк районнарындагы һәм аларга тиңләштерелгән урыннардан соңгы яшәү урыныннан күрсәтелгән районнарда һәм җирдә төп чарада катнашу турында гариза биргән граждан белән туганнарының (ире яки хатыны, балалары, әти-әнисе, уллыкка алынган, уллыкка алучылардан тыш) даими яшәүләрен һәм әлеге гражданин белән Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән урыннардан килгән эшкә сәләтсез асрама (иждивенец), аның белән сайланган урында даими яшәвен һәм аның белән гомуми хуҗалык алып баруын раслаучы йорт кенәгәсеннән өземтә (фатир саен бирелә торган картаның күчермәсе) (әгәр күрсәтелгән туганнары һәм эшкә сәләтсез иждивенцлар элеккеге яшәү урыны буенча аның гаилә әгъзалары буларак урнаштырылганнар һәм аның белән бергә гомуми хуҗалык алып барган булсалар), - әлеге Кагыйдәләрнең (Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдән чыгып китүче (киткән), "Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдән чыгып китүче гражданнарга торак субсидияләре турында" Федераль закон нигезендә социаль түләү алу хокукына ия) Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдән 1992 елның 1 гыйнварыннан 2015 елның 1 гыйнварына кадәр чыгып китүче гражданнар өчен;

**Ата-ана белән янәшә яшәүче һәм үз гаиләсен кормаган биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр категориясе буенча торак урынына мохтаҗлар буларак исәпкә кую мәсьәләсен карау өчен кирәкле документлар исемлеге***

1. Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гариза
2. күпбалалы ана таныклыгы.
3. гаиләнең һәр әгъзасына шәхесен таныклаучы документлар күчермәләре (паспорт, туу турында таныклык, барлык битләр);
4. никах турында таныклык (тулы булмаган гаиләгә кагылмый);
5. йорт кенәгәсеннән өземтә
6. финанс шәхси счет күчермәсе;
7. Бердәм дәүләт хокук реестрыннан ир белән хатынның икесенә дә күчемсез милек объектларына хокукын теркәү турындагы белешмәләрнең булмавы турында өземтә.
8. ир белән хатынның икесенә дә теркәлү урыны буенча торак булу яки булмавы турында Техник инвентаризация бюросыннан белешмә

**Ятим балалар, ата - ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясе буенча торак урынына мохтаҗлар буларак исәпкә кую мәсьәләсен карау өчен кирәкле документлар исемлеге***

1. Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алу турында гариза
2. паспорт кучермәсе (барлык битләр);
3. юридик статусны раслый торган документлар күчермәләре (ата-аналар үлеме турында таныклыкның күчермәләре, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында суд карарының

күчермәләре, ата-ананы эзләү турында Эчке эшләр органнарыннан белешмә, ата-ананы эшкә сәләтсез дип тану турында суд карары, ата-аналарның булмавын раслаучы башка документлар);
4. теркәлү урыны буенча йорт кенәгәсеннән өземтә,
6. теркәлү урыны буенча финанс-шәхси счет күчермәсе;
7. теркәлү палатасыннан теркәлү урыны буенча милектә торак булмау турында белешмә.
8. теркәлү урыны буенча милкендә торак булмау турында Техник инвентаризация бюросының белешмәсе.

**Искәрмә**

* Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларны гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы

Зче кушымта
Административ регламентка

**Бинаны тикшерү**
**АКТЫ**

№ ________________________________ ________________________________
(дата)

ТР, Чирмешән муниципаль районы, ________________________________

(бинаның урнашу урыны, шул исәптән торак пункты һәм урам исемнәре, йорт һәм фатир номерлары)

Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең № _____ _______________ карары белән билгеләнгән объектларның техник торышын тикшерү буенча комиссия _______________

(кем белән билгеләнгән, башкарма хакимиятнең, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы исеме, комиссия чакырылышы турында карарның датасы, номеры)

составында рәис ________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазыйфасы һәм эш урыны)

комиссия секретаре
һәм әгъзалары: ________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм вазыйфасы)

һәм чакырылган торак милекчесе яки аның вәкаләтле заты

________________________

________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазыйфасы һәм эш урыны)

________________________________

физик зат өчен, оешма исеме һәм биләгән вазыйфасы - юридик зат өчен)
түбәндәге адрес буенча урнашкан бинаны тикшерү буенча әлеге актны төзеде: Чирмешән муниципаль районы ________________________________

(адресы, бинаның каравы,

районы ________________________________

кадастр номеры, файдалануга тапшыру елы)

Торак бина, бинаның инженерлык системалары, җиһазлар һәм механизмнар һәм бина янәшәсендәге территория торышының кыскача тасвирламасы ________________________________

________________________________

________________________________

________________________________

**Күрсәткечнең факттагы мәгънәләрен күрсәтеп яисә төгәл туры килмәүне тасвирлап, билгеләнгән таләпләргә туры килмәү турында белешмәләр.** ________________

**Үткәрелгән инструменталь контроль һәм башка төр контроль һәм тикшеренүләр нәтиҗәләрен бәяләү**

(кем тарафыннан контроль (сынау) үткәрелде, нинди күрсәткечләр буенча, нинди факттагы күрсәткечләр алынган)

**Ведомствоара комиссиянең тәкъдимнәре һәм даими яшәү өчен куркынычсызлыкны тәэмин итү яки нормаль шартлар булдыру өчен тәкъдим ителә торган чаралар:**

**Бинаны тикшерү нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия бәяләмәсе.**

__________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________.

Ведомствоара комиссия рәисе

| | |
|---|---|
| ______________________ | _______________________________________ |
| (имза) | (Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме) |

Ведомствоара комиссия секретаре

| | |
|---|---|
| ______________________ | _______________________________________ |
| (имза) | (Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме) |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| ______________________ | _______________________________________ |
| (имза) | (Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме) |
| ______________________ | _______________________________________ |
| (имза) | (Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме) |
| ______________________ | _______________________________________ |
| (имза) | (Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме) |

5нче кушымта
Административ регламентка
(белешмә)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары,**

Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | **2-58-00** | Ilfat.Shaydullin@tatar.ru |
| Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | **2-58-15** | Karimov.Ildus@tatar.ru |
| Башкарма комитет эшләре идарәчесе | **2-58-17** | Ilnur.Zamaletdinov@tatar.ru |
| Бүлек начальнигы | **2-23-69** | G.ElviraV@tatar.ru |

Чирмешән муниципаль районы Советы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башлык | **2-59-00** | Cheremshan@tatar.ru |